| | |
|---|---|
| ГЛАВА ХОЗЕСАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 ноябрь 2024 ел Хужа Хәсән авылы №6

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Хужа Хәсән авыл җирлегенең
Кушкүл торак пунктында гражданнар
җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2024 елның 29 ноябренә 13 сәг 00 минутка Кушкүл ав., 1 Май ур., 11 йорт адресы буенча урнашкан Кушкүл авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хужа Хәсән авыл җирлегенң Кушкүл торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Хужа Хәсән авыл җирлегенең Кушкүл авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- материаллар сатып алып чишмәне төзекләндерү һәм ремонтлау;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын

һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Хужа Хәсән авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Хужа Хәсән авыл жирлеге Башлыгы: С.П.Матвеева